КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1042

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 7 март, 165 нче; 2019 ел, 17 май, 402 нче; 2019 ел, 13 июль, 572 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1006 нчы; 2020 ел, 18 февраль, 123 нче; 2020 ел, 27 апрель, 331 нче; 2020 ел, 9 июнь, 477 нче; 2020 ел, 24 июль, 622 нче; 2020 ел, 9 июнь, 477 нче; 2020 ел, 24 июль, 622 нче; 2020 ел, 5 сентябрь, 790 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

39 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «39. | «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләрне кертү һәм традицияләрне саклап калу буенча ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | | 3 | җиңел автомобиль | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | микроавтобус/фургон | 26 730 | 110»; |

41 һәм 48 нче пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

түбәндәге эчтәлекле 21 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «21. | «Регби буенча республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе | | 1 | җиңел автомобиль | 17 010 | 70»; |

«Барлыгы» юлында «75» саннарын «76» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларындагы (иң чик санындагы) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлындагы 4 нче пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Аквакультура һәм умартачылык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

4 нче пунктның 4 графасында «9» санын «10» саннарына алыштырырга;

«Барлыгы» юлында «117» саннарын «118» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин